| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТИХОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　К А Р А Р

2020 елның 27 августыннан　　　　　　　　　　№ 161

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясендә үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 19 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 5 сентябреннән 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2013 елның 28 маеннан 7 номерлы Тихоново авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрен Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының 2014 елның 01 сентябрендәге 540 номерлы Боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре Классификаторына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 маеннан 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Тихоново авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;

- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы Карары проектын карап тикшерү буенча гавами тыңлаулар 2020 елның 27 асентябрендә 17 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тихоново авыл җирлеге, Тихоново авылы, Коммунистлар ур., 27В йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге мәдәният йортының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең “Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы карар проекты белән танышу чорында югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәләр: Татарстан Республикасы, Тихоново авыл җирлеге, Тихоново авылы, Коммунистлар ур., 27В йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге мәдәният йортының актлар залы;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында бастырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Тихоново авыл җирлеге
Советы рәисе А.М. Карманов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге
Советының
2020 елның 27 августыннан
161 номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тихоново авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Карманов Алексей Михайлович - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Рәис урынбасары: Галкин Григорий Андреевич - Тихоново авыл мәдәният йорты директоры;
3. Секретарь: Гусева Алина Владимировна – Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Филатов Александр Александрович – Тихоново авыл җирлеге Советы Депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Валеева Елена Константиновна – Тихоново авыл җирлеге Советы Депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы Инвестицион һәм инфраструктур үсеш идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.